**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 382

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.91 – 3.3.98 пунктчалар өстәргә:

«3.3.91. Татарстан Республикасы милкендәге социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарында вакытлыча тору шартнамәләрен төзү һәм үтәүгә Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең наемга бирүче тарафыннан үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3.92. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җирләрне республика әһәмиятендәге аеруча саклана торган җирләр дип карау турында карарлары проектларын килештерә.

3.3.93. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә карата коммерциядә кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукционның, социаль кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукционның башлангыч бәясен билгели.

3.3.94. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә карата коммерциядә кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукционнар, социаль кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукционнар үткәрә.

3.3.95. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә карата коммерциядә кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамәләр, социаль кулланылган наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамәләр төзи.

3.3.96. Министрлык, шулай ук Минисрлык карамагындагы оешмалар хезмәткәрләрен террорчылык актлары куркынычын кисәтү, аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү алымнарына өйрәтүне оештыра.

3.3.97. Террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының үзара багланышларын көчәйтү максатларында укулар үткәрүдә катнаша.

3.3.98. Министрлыкка беркетелгән объектларны террорчылыктан саклауны тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков